КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 октябрь г.Казань № 913

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешманың иң югары коллегиаль органы – Күзәтүчеләр советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешма уставын раслау һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешманың Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 11 февраль, 83 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 август, 550 нче, 2016 ел, 23 август, 586 нчы, 2017 ел, 24 апрель, 243 нче; 2018 ел, 27 март, 177 нче, 2019 ел, 03 август, 640 нчы, 2020 ел, 03 июнь, 462 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешманың иң югары коллегиаль органы – Күзәтүчеләр советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Р.Т.Борһановны Күзәтүчеләр советы составыннан чыгарырга;

Күзәтчеләр советы составына Һадиуллин Илсур Гәрәй улын, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын кертергә;

Хәйруллин Айрат Ринат улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры»;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы икътисад министры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин